| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| 21.06.2023 | г. Казань | № 467/2023 |

**Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә

Б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыклары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 17.01.2020 № 6;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын

раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 04.08.2020 № 290/2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 18.12.2020 № 704/2020;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 22.10.2021 № 588/2021;

3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары Л.В.Хәбибуллинага йөкләргә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 21.06.2023 №467/2023
номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган оешмаларның инвестиция программаларын раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыра торган юридик затлар яисә шәхси эшкуарлар.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы.

Татарстан Республикасы территориясендә җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын раслау.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты)

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтү каралмаган.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе.

2.3.1. Дәүләт комитетының рәсми сайтында бастырылган, Дәүләт комитетының инвестиция программасын раслау (инвестиция программасына үзгәрешләр кертү) турында боерыгы яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хат.

2.3.2. Дәүләт комитетының инвестиция программасын раслау (инвестиция

программасына үзгәрешләр кертү) турындагы боерыгы реквизитлары:

инвестиция программасын раслау турында боерыкның номеры һәм датасы;

инвестиция программасын раслау турында боерык кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның (алга таба – вәкаләтле зат) вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

вәкаләтле затның имзасы.

Инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерүгә юнәлтү турында хатның реквизитлары:

карар кабул итүгә вәкаләтле органның исеме;

карар кабул итүгә вәкаләтле затның вазыйфасы;

вәкаләтле затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

вәкаләтле затның имзасы яки электрон имза турында мәгълүмат.

2.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып реестр язуы тормый.

2.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында электрон почта һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – Портал) шәхси кабинетына җибәреп.

2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы.

2.4.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән, почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, электрон документ әйләнеше системасы аша тапшырылган очракта, Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәгечә күрсәтелә:

инвестиция программасын гамәлгә ашыру башланган чорга кадәрге елның 30 октябренә кадәр;

Дәүләт комитетына инвестиция программасына үзгәрешләр кертү турында тиешле гариза җибәрелгән елның 20 ноябренә кадәр;

гариза һәм инвестиция программасы проектын, шул исәптән концессия килешүе нигезендә эшләнгән инвестиция программасы проектын раслау өчен җибәргәннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча (концессия килешүе үз көченә керүнең беренче елында).

Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте, әгәр дә гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Порталдагы шәхси кабинет аша тапшырылган булса, гаризага эш номенклатурасы һәм Порталдагы шәхси кабинетта чагылдырылган «Документларны тикшерү» статусына ярашлы рәвештә номер бирелгән көннән алып әлеге пунктта күрсәтелгән срокларда күрсәтелә.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр.

Порталда, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар;

Дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче, мөрәҗәгать категориясенә һәм нигезенә бәйсез рәвештә, гариза тапшыра:

- турыдан-туры Дәүләт комитетына яисә почта аша мөрәҗәгать иткәндә кәгазь чыганактагы документ рәвешендә (әлеге Административ регламентка 1 нче кушымта) ;

- Портал аша мөрәҗәгать иткәндә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон формада (гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүмат кертү юлы белән тутырыла);

- электрон формада, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ әйләнеше системасы ярдәмендә мөрәҗәгать иткәндә;

- электрон формада электрон документ рәвешендә документның оригиналыннан турыдан-туры сканерлау юлы белән (копияләрне куллану рөхсәт ителми), ул документ оригиналының ориентациясен 300 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә саклап, электрон почта аша җибәргәндә башкарыла.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына мөрәҗәгать иткәндә гариза белән бергә әлеге Административ регламентның 2 нче кушымтасында күрсәтелгән документларны һәм материалларны тапшыра.

2.6.3. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар алу каралмаган.

2.6.5. Гариза җайга салынулы оешманың җитәкчесе яки башка вәкаләтле заты тарафыннан имзалана, җайга салынулы оешманың мөһере (булган очракта) белән таныклана һәм теркәлә торган нигезләү материаллары исемлеген үз эченә ала.

2.6.6. Гаризага теркәп тапшырыла торган документлар һәм материаллар төп нөсхәдә яки мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган күчермәләрдә тапшырыла.

2.6.7. Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырылган.

2.6.8. Инвестиция программасы (инвестиция программасына төзәтмә) нигезләү материаллары белән җайга салына торган оешма тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тәкъдим ителергә (юнәлдерелергә) мөмкин:

җайга салу органы җитәкчесе тарафыннан шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш иткән зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында белдереп, теркәлгән документлар исемлеге белән почта юлламасы итеп.

2.6.9. Инвестиция программасы (инвестиция программасына төзәтмә) нигезләү материаллары белән шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан Портал, электрон документ әйләнеше системасы, электрон почта аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә

тәкъдим ителергә (җибәрелергә) мөмкин.

Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg – формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла.

2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып әлеге Административ регламентның 1.2 пунктына ярашлы рәвештә гариза бирүче булмаган кешенең документлары белән мөрәҗәгать итүе тора.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

а) җайга салынулы оешма тарифларының кулланучылар өчен куллана алырлык булмавы (тарифларны куллана алырлык булмау сәбәпле баш тарту концессионер тарафыннан концессия килешүе нигезендә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системасы объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү буенча йөкләмәләрен үти алмау ихтималын китереп чыгара торган очраклардан

тыш);

б) төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый тәэмин итү функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимиятн органы тарафыннан расланган җитештерү булмаган объектлар һәм инженерлык инфраструктурасы объектлары өчен эреләндерелгән смета нормативлары буенча билгеләнгән чараларның инвестиция программасында каралган чараларны гамәлгә ашыру чыгымнарын арттырып җибәрүе;

в) раслана торган инвестиция программасына концессия килешүе нигезендә кертелгән чараларны гамәлгә ашыру һәм җайга салынулы оешманың концессия килешүе үз көченә кергәннән соң расланган һәм концессия килешүенә кертелгән чараларны, тоташтырган (техник ялгаган) өчен түләү хисабына финанслана торган чаралардан тыш, үз эченә алган инвестиция программасына концессия килешүе нигезендә кертелгән чараларны гамәлгә ашыру чыгымнары суммасының, концессия килешүе объектын булдыру һәм (яки) үзгәртеп кору һәм (яки) модернизацияләү, әхлакый тузган һәм физик таушалган, концедент тарафыннан концессия килешүе буенча концессионерга тапшырыла торган башка мөлкәтне тагын да җитештерелешлерәк, мондый мөлкәтнең характеристикалары һәм файдалану үзлекләре башкача яхшырак булган яңа мөлкәткә алмаштыру (концессия килешүе нигезендә концессионер гамәлгә ашырырга планлаштырган) чыгымнарының чик суммасының артып китүе.

2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары.

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артык булырга тиеш түгел.

Югарыда күрсәтелгән көтү вакытына төшке аш вакыты һәм эш вакыты булмаган вакыт кертелми.

Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры.

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгате кирәкле барлык документлары белән гариза алынган көнне теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

2.12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында

(бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – Объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) Объектлардан һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

б) территория буенча мөстәкыйль рәвештә яки дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр ярдәмендә хәрәкәт итү, мондый Объектларга керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

в) Объектларга керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга Объектларда ярдәм күрсәтү;

д) инвалидларның Объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләреннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

е) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, тавыш ярдәмендә һәм күрсәтмә мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокта шрифтлары белән һәм контраст фонында башкарылган текстлы һәм графиклы башка мәгълүматны кабатлап күрсәтү, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене, шулай ук ишарә телен белә торган башка затны кертү;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июлендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, Объектларга сукырларны озата йөри торган этне кертү;

з) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар өчен үтемле формада дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен аңлатуга, аны күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерүгә, инвалидларны кабинетларның урнаштырылу тәртибе белән таныштуыруга, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле гамәлләр эзлеклелегенә бәйле кирәкле ярдәмне күрсәтү;

и) инвалидларның яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән файдалана алу мөмкинлеге;

к) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү.

2.12.4. 2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу

күрсәткечләре.

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;

дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан әлеге Административ регламент бозылу очракларына карата нигезләнгән шикаятьләрнең булмавы;

мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре белән шәхси мөрәҗәгать иткәндә үзара бәйләнешкә керү саны икедән артмый (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.2. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре:

документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;

Мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат ресурсларында, Порталда тулы мәгълүмат булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтләреннән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый.

2.13.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Порталдан алынырга мөмкин.

2.13.5. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында.

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Гаризаны электрон документ рәвешендә Портал (http://uslugi.tatarstan.ru) аша тапшыру мөмкинлеге бар.

2.14.3. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Порталда урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны да, Порталдан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы

гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) Порталдан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Портал, дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.4. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Порталда гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Порталда БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелә.

Гариза Бердәм портал аша җибәрелгән очракта, әлеге Административ регламентның 2.3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Порталда шәхси кабинетка Дәүләт комитеты җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.5. Җайга салу оешмаларын Дәүләт комитетына кабул итүгә язу гамәлгә ашырылмый.

2.14.6. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы кулланылмый.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә Дәүләт комитеты рәсми сайтында (http://kt.tatarstan.ru) һәм Порталда (http://uslugi.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

Язма мөрәҗәгать буенча Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган хезмәткәре мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибен җентекле рәвештә язмача аңлатып бирә һәм законнарда билгеләнгән срок эчендә мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрә. Җаваплар мөрәҗәгать итү телендә бирелә. Мөрәҗәгать итү телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасы дәүләт телләре кулланыла.

2.14.8. КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп, дәүләт хезмәте күрсәтү КФҮ гамәлгә ашырылмый.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү вариантлары исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм реестр язуларында бирелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү өчен кирәкле дәүләт хезмәте күрсәтү

вариантлары.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм булдырылган реестр язуларында җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү бердәм вариантта гамәлгә ашырыла һәм дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары, мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре, түләү күләме һәм тәртибе, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган документлар һәм юридик яктан әһәмиятле гамәлләр белән аерыла.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын бирү өчен вариантлар исемлеге, шул исәптән мондый дубликатны бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документ дубликаты бирелми.

3.3. Мөрәҗәгать итүчене бер профильдән икенче профильгә җибәрү административ процедурасына тасвирлама: мөрәҗәгать итүченең профилен үзгәртү процедурасы башкарылмый.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

1) Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, Мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

2) гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү;

3) Мөрәҗәгать итүче тапшырган материалларны эшкәртү һәм анализлау барышында документларны билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве буенча тикшерү һәм җирле үзидарә органына килештерү өчен җибәрү;

4) исәпләмәләрне һәм тапшырылган материалларны анализлау, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың инвестиция программасын раслау турында карар кабул итү яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү зарурлыгы турында карар кабул итү;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 28 сентябрендәге 1728-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасы электр энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын һәм инвестиция программаларын үтәү турындагы хисапларын карау буенча экспертлар советы утырышын әзерләү һәм үткәрү (алга таба – Экспертлар советы, 1728-р номерлы күрсәтмә);

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

7) расланган инвестиция программасына үзгәрешләр кертү;

8) техник хатаны төзәтү.

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза төзү өлешендә дә.

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Дәүләт комитетына шәхсән, телефон, электрон почта һәм (яисә) «Татарстан Республикасы рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы»

аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Инвестиция программалары бүлеге (алга таба – Бүлек) белгече шәхсән, телефон, электрон почта аша, язмача һәм (яки) хат аша мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләрдә дә, шулай ук, кирәк булганда, гариза рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гаризаның һәм тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә консультация, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.6. Гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итү һәм теркәү.

3.6.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, электрон документ әйләнеше системасы, Портал, электрон почта аша Дәүләт комитетына гариза бирә һәм әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә аңа документлар һәм материаллар тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: җайга салына торган оешма тарафыннан бирелгән гариза һәм аңа материаллар.

3.6.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны Портал аша электрон формада кабул итү

3.6.2.1. Портал аша электрон формада гариза тапшыру өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Порталда авторизацияләнә;

Порталда гаризаның электрон формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә;

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга билгели);

хәбәр ителгән мәгълүматның дөреслеген раслый;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җайга салынган оешма тарафыннан Портал аша бирелгән гариза.

3.6.3. Дәүләт комитетына документлар рәвешендә кергән, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документларны кабул итү.

3.6.3.1. Гаризаны документлар рәвешендә бирү өчен мөрәҗәгать итүче әлеге Административ регламентның 2.6 пункты нигезендә документлар комплектын формалаштыра һәм гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлегенә шәхсән үзе тапшыра, яисә почта юлламасы белән җибәрә.

3.6.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар комплектын карау.

Әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булган очракта, гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече документларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтара.

Документларны кабул итүдән әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре турында телдән хәбәр итә һәм, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, барлык документларны аңа кайтарып бирә. Гаризаны һәм документларны Портал, электрон документ әйләнеше системасы, электрон почта аша гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече гаризаны һәм документларны, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту сәбәпләрен язмача аңлатып, кайтарып бирә.

Әлеге Административ регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече:

гаризаны кабул итә;

гаризаны беренчел эшкәртә һәм, теркәлү номеры беркетеп һәм кабул итү көнен күрсәтеп, гаризаны электрон документ әйләнеше системасында терки;

мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итү датасы, кабул иткәндә бирелгән номеры турында тамга белән гариза күчермәсен тапшыра (кәгазь чыганакта гариза бирелгән очракта), яисә җавап хәбәрен электрон почта аша җибәрә (гариза электрон почта аша җибәрелгән очракта) яки Порталга мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына җибәрә (гариза Портал аша бирелгән очракта).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән гариза.

Тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм алып бару бүлеге белгече гаризаны электрон документ әйләнеше системасы аша электрон формада рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелгән гариза.

Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) гаризаны карый һәм тикшерү өчен җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә инвестиция программаларын раслау мәсьәләләрен алып баручы рәис урынбасарына (алга таба – рәис урынбасары) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәү көненнән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис урынбасарына карау өчен җибәрелгән гариза.

Рәис урынбасары гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карап тикшерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек җитәкчесенә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

Бүлек башлыгы гаризаны карый, җаваплы башкаручыны билгели һәм карау өчен аңа җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җаваплы башкаручыга җибәрелгән гариза.

3.7. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә карата тикшерү.

Инвестиция программасы әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктында каралган таләпләргә туры килсә, Дәүләт комитеты инвестиция программасын җирле үзидарә органына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгән көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасы килештерү өчен тиешле җирле үзидарә органына җибәрелә.

3.7.1. Инвестиция программасы әлеге Административ регламентның 2.6.2 пунктында каралган таләпләргә туры килмәгән очракта, Бүлек белгече Мөрәҗәгать итүчегә инвестиция программасының эшләп бетерүне таләп итә торган бүлекләрен (пунктларын) күрсәтеп, инвестиция программасын мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирү турында хәбәр әзерли, аңа рәис яисә Бүлек эшен алып бара торган рәисе урынбасары кул куя һәм әлеге хәбәр мөрәҗәгать итүчегә почта юлламасы итеп җибәрелә яки кулга тапшырыла, яисә электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм докумантларны теркәгәннән соң җиде көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кисәтүләрне бетерү зарурлыгы турында имзаланган хәбәр.

3.7.2. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына законнарда билгеләнгән срокта эшләп бетерелгән инвестиция программасын тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: эшләп бетерелгән инвестиция программасы.

3.7.3. Эшләп бетерелгән инвестиция программасы әлеге Регламентның 3.6 пунктында билгеләнгән тәртиптә теркәлә һәм Бүлек белгеченә тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура эшләп бетерелгән инвестиция программасы кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: эшләп бетерелгән инвестиция программасын теркәү.

3.7.4. Дәүләт комитеты эшләп бетерелгән инвестиция программасын җирле үзидарә органына килештерү өчен җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура эшләп бетерелгән инвестиция программасын теркәгән көннән алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен тиешле җирле үзидарә органына җибәрелгән эшләп бетерелгән инвестиция программасы.

Законнарда билгеләнгән срокта җирле үзидарә органы Дәүләт комитетына кабул ителгән карар турында хәбәр итмәсә, инвестиция программасы килештерелгән була.

3.8. Исәпләмәләрне һәм тапшырылган материалларны анализлау, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы

оешманың инвестиция программасын раслау турында карар кабул итү яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү зарурлыгы турында карар кабул итү.

Җирле үзидарә карарының Дәүләт комитетына килүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

3.8.1. Җирле үзидарә органы инвестиция программасын килештермәгән очракта, Дәүләт комитеты аны Мөрәҗәгать итүчегә өстәмә эшләү һәм кисәтүләрне бетерү өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура инвестиция программасын килештерүдән баш тарту турында җирле үзидарә органы карары кергән көннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: өстәмә эшләү һәм кисәтүләрне бетерү өчен юнәлдерелгән инвестиция программасы.

3.8.2. Дәүләт комитетына инвестиция программасын килештерү турында җирле үзидарә органы карары кергән очракта, Бүлек белгече түбәндәге тикшерүләрне үткәрә:

тапшырылган документлардагы белешмәләрнең үзара туры килү-килмәвен тикшерә;

тапшырылган документларның формасы һәм эчтәлеге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерә;

инвестиция программасы чараларының каралган программа чараларын территориясендә гамәлгә ашыру күздә тотылган муниципаль берәмлекне җылылык белән тәэмин итү схемасына туры килү-килмәвен тикшерә;

җылылык белән тәэмин итүгә тарифлар раслаганда гамәлгә кертү өчен күздә тотылган инвестиция программасын финанслау чаралары һәм чыганакларының Дәүләт комитеты исәпкә алган күләмнәренең табыштан, амортизациядән һәм үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системаларына технологик ялгау өчен түләүдән алынган капитал кертемнәре зурлыкларына туры килү-килмәвен тикшерә;

инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле чаралар күләменең җитештерүгә бәйле булмаган билгеләнештәге объектлар һәм инженерлык инфраструктурасы өчен Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган эреләндерелгән смета нормативларына (алга таба – эреләндерелгән смета нормативлары) туры килү-килмәвен тикшерә;

профильлек бүлек белгечләре белән берлектә, коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар түләвенә карата Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар түләве артуның җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифлар билгеләгәнә Мөрәҗәгать итүченең инвестиция программасын гамәлгә ашыру чыгымнарын исәпкә алу белән аңлатылган темпларын анализлау нигезендә кулланучылар өчен аның тарифларының мөмкинлекле булуын бәяли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура җирле үзидарә органыннан килештерү алынган көннән башлап 20 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: әлеге Административ регламентның 3.9 пунктында билгеләнгән тәртиптә Экспертлар советы утырышын әзерләү һәм

үткәрү яки инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында язма хәбәр итү.

3.8.3. Дәүләт комитеты инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында карар кабул иткәндә һәм аны әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр буенча эшләп бетерү өчен җибәргән очракта, Бүлек белгече инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү зарурлыгы турында язмача хәбәр әзерли, аңа рәис яисә рәиснең урынбасары тарафыннан кул куела һәм ул Мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар карар кабул ителгән көннән башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында язма хәбәр әзерләү һәм җибәрү.

3.8.4. Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына законнарда билгеләнгән срокта эшләп бетерелгән инвестиция программасын тапшыра.

Процедураның нәтиҗәсе: эшләп бетерелгән инвестиция программасы Дәүләт комитетына карап тикшерү өчен җибәрелә.

3.8.5. Эшләп бетерелгән инвестиция программасы әлеге Административ регламентның 3.6 пунктында билгеләнгән тәртиптә теркәлә һәм Бүлекнең административ процедураны үтәү өчен җаваплы белгеченә тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура инвестиция программасы һәм гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән инвестиция программасы.

3.8.6. Дәүләт комитеты эшләп бетерелгән инвестиция программасын җирле үзидарә органына килештерү өчен яңадан җибәрә.

Шул ук вакытта, әгәр аны эшләп бетерү нәтиҗәсендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру исемлеге, составы һәм сроклары үзгәрмәгән булса, эшләп бетерелгән инвестиция программасын җирле үзидарә органы белән килештерү таләп ителми.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура инвестиция программасы тапшырылган көннән алып өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тиешле җирле үзидарә органына кабат килештерү өчен юнәлдерелгән инвестиция программасы.

3.8.7. Җирле үзидарә органы килештергәннән соң (кирәк булганда) Бүлек белгече әлеге Административ регламентның 3.8.2 пунктында каралган процедураны гамәлгә ашыра һәм Дәүләт комитеты тарафыннан инвестиция программасын карау нәтиҗәләре турында бәяләмә проектын әзерли һәм аны әлеге юнәлештә эшләүче Дәүләт комитеты рәисе урынбасарына инвестиция программасын теркәп тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура биш календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын карау нәтиҗәләре турында бәяләмә проекты.

3.8.8. Рәис урынбасары тапшырылган бәяләмә проектын һәм инвестиция программасын карый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура бәяләмә проекты һәм инвестиция программасы карауга кергән көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Дәүләт комитеты тарафыннан инвестиция

программасын раслаудан баш тарту һәм аны әлеге Административ регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр буенча эшләп бетерүгә җибәрү турында карар кабул итү яисә Экспертлар советы утырышына фикер алышуга инвестиция программасын кертү турында карар кабул итү.

3.9. Экспертлар советы утырышын әзерләү һәм уздыру.

Экспертлар советы утырышларында инвестиция программаларын карау 1728-р номерлы боерык белән расланган Экспертлар советы турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура 10 календарь көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Экспертлар советының инвестиция программасын раслау яисә инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында Экспертлар советы беркетмәсе белән рәсмиләштерелгән һәм Рәис тарафыннан имзалаган карары.

3.10. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен әзерләү.

3.10.1. Экспертлар советы утырышында инвестиция программасын раслау турында карар кабул ителгән очракта, Бүлек белгече Дәүләт комитетының инвестиция программасын раслау турындагы боерыгы проектын әзерли һәм аны Бүлек җитәкчесенә, юридик бүлек җитәкчесенә һәм рәис урынбасарына килештерү өчен җибәрә.

Дәүләт комитеты инвестиция программасын инвестиция программаларын гамәлгә ашыра башлаган чор алдыннан килгән елның 30 октябренә кадәр раслый.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура Экспертлар советы утырышы уздырылган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслау турында боерык проекты.

3.10.2. Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе һәм рәис урынбасары инвестиция программасын раслау турында боерык проектын карыйлар, килештерәләр һәм имзалау өчен рәискә җибәрәләр.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек җитәкчесе, юридик бүлек җитәкчесе, җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә тарифларны җайга салу һәм контрольдә тоту бүлеге җитәкчесе һәм рәис урынбасары тарафыннан килештерелгән, имзалау өчен рәискә җибәрелгән инвестиция программасын раслау турында боерык проекты.

3.10.3. Рәис инвестиция программасын раслау турында боерык проектын карый, имзалый, гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлегенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәис тарафыннан имзаланган инвестиция программасын раслау турындагы боерык.

3.10.4. Инвестиция программасын раслау турында боерык кабул ителгән очракта, Бүлек белгече инвестиция программасын раслау турында карарны Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура инвестиция программасын раслау турындагы боерык рәис тарафыннан имзаланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: рәсми сайтта инвестиция программасын раслау турында карар урнаштыру.

3.10.5. Экспертлар советы утырышында инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында карар кабул ителгән очракта, Бүлек белгече инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында язма хәбәр әзерли һәм Бүлек җитәкчесе белән алдан килештереп, аны имзалау өчен рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында язма хәбәр проекты.

3.10.6. Рәис урынбасары язма хәбәргә кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында имзаланган язма хәбәр.

3.10.7. Гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару бүлеге белгече:

инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм эшләп бетерү кирәклеге турында язма хәбәрне терки һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән инвестиция программасын раслаудан баш тарту һәм аны эшләп бетерү кирәклеге турында язма хәбәр.

3.11. расланган инвестиция программасына үзгәрешләр кертү.

3.11.1. Инвестиция программасына үзгәрешләр кертү (инвестиция программасына төзәтмәләр кертү) зарурлыгы булган очракта, күрсәтелгән үзгәрешләр Дәүләт комитеты тарафыннан расланырга тиеш. Инвестиция программасына үзгәрешләр кертү гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Инвестиция программасына (шул исәптән агымдагы елга расланган) үзгәрешләр кертү турында гаризаны мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт комитетына тапшыру инвестиция программасына кертелә торган үзгәрешләр проекты белән берлектә һәм әлеге Административ регламентның 9 нчы кушымтасы нигезендә рәсмиләштерелгәнчә аларны нигезләү законнарда каралган тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитетына инвестиция программасына үзгәрешләр кертү турында гариза белән мөрәҗәгать итүе.

3.11.2. Инвестиция программасына үзгәрешләр кертү әлеге Административ регламентның 2.4.1 пунктының 3 абзацында һәм 3.6-3.10 пунктларында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда башкарыла.

3.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, Мөрәҗәгать итүче Дәүләт комитетына түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (10 нчы кушымта);

Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хатасы барлыгын дәлилли торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мәгълүматларындагы техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша, электрон почта яки электрон документ әйләнеше системасы аша җибәрелә.

3.12.1. Документларны кабул итү өчен җаваплы гомуми тәэмин итү һәм эш алып бару белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, гаризаны теркәп тапшырылган документлары белән бергә терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер календарь көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән гариза.

3.12.2. Бүлек белгече документларны карап тикшерә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка үзгәрешләр кертү максатларында шушы Административ регламентның 3.10 пунктында каралган процедураларны башкара һәм яңадан үзгәртеп рәсмиләштерелгән документны Мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкилгә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкилдән) техник хатасы булган документның төп нөсхәсен алып калып тапшыра яки Мөрәҗәгать итүче адресына почта (электрон почта) аша яисә электрон документ әйләнеше системасы буенча Бүлеккә техник хатасы булган документның төп нөсхәсен тапшырган очракта документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (почта яки электрон адрес буенча җибәрелгән) җавап.

## 4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

